СОВЕТ
СТАРОДРОЖЖАНОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ДРОЖЖАНОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧҮПРӘЛЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ИСКЕ ЧҮПРӘЛЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

---

**РЕШЕНИЕ** с. Старое Дрожжаное **КАРАР**

09.04.2024 ел № 45/1

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставының 32 статьясындагы 1 пунктының 1 пунктчасы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставына кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Идарәсендә дәүләт теркәвеннән соң әлеге карарны Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставына ярашлы рәвештә бастырып чыгарырга һәм Чүпрәле муниципаль районының рәсми сайтында Интернет челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге Карар, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, рәсми басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы: М.Р. Гафаров

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Советының 2024 елының 09 апрелдагы 45/1 номерлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Иске Чүпрәле авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

1) **7 статьясының 1 пунктындагы 12 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«12) балалар һәм яшьләр белән эшләү чараларын оештыру һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда катнашу, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләү һәм гамәлгә ашыру, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләү һәм гамәлгә ашыру, Җирлектә яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыру һәм гамәлгә ашыру;»;

2) **32 статьясының 1 пунктының 29 пунктчаны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«29) муниципаль хокукый актларны игълан итү, муниципаль берәмлек халкына рәсми мәгълүмат җиткерү өчен басма массакүләм мәгълүмат чарасы һәм (яки) челтәр басмасы оештыру;»;

3) **42 статьяны** түбәндәге эчтәлектәге **3.2 нче пункт** белән тулыландырырга:

«3.2. Җирлек башлыгы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 декабрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу таләпләрен һәм бурычларыны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә тикшерү тарафыннан аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе булып танила икән, җаваплылыктан азат ителә.».

4) **48 статьясындагы 10 нчы пунктны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) балалар һәм яшьләр белән эшләү буенча чаралар оештыра һәм гамәлгә ашыра, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруда, яшьләрнең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау чараларын эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда, яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруның төп юнәлешләре буенча муниципаль программаларны эшләүдә һәм гамәлгә ашыруда катнаша, торак пунктта яшьләр сәясәтен гамәлгә ашыруны мониторинглауны оештыра һәм гамәлгә ашыра;»;

5) **49 статьяны** түбәндәге эчтәлекле **4.2 өлеше** белән тулыландырырга:

«4.2. Башкарма комитет җитәкчесе, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 декабрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу таләпләрен һәм бурычларыны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә тикшерү тарафыннан аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе булып таныла икән, җаваплылыктан азат ителә.».

**6) 64.2 статьяны** түбәндәге эчтәлектәге **4 пункт** белән тулыландырырга:

«**4**. Депутат, җирле үзидарәнең сайлап куелган органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайлап куелган вазыйфаи заты, муниципаль вазыйфаны биләүче бүтән зат, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 декабрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм башка федераль законнар белән билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны, мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу таләпләрен һәм бурычларыны үтәмәгәне өчен, әгәр мондый чикләүләрне, тыюларны һәм таләпләрне үтәмәү «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясының 3-6 өлешләрендә каралган тәртиптә тикшерү тарафыннан аңа бәйле булмаган хәлләрнең нәтиҗәсе булып таныла икән, җаваплылыктан азат ителә.».

**7) 75 статьяны** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«75 статья**.** Муниципаль хокукый актларны халыкка җиткерү һәм аларның үз көчләренә керү тәртибе»

1. Кеше һәм гражданның хокукларына, ирекләренә һәм бурычларына кагылышлы муниципаль норматив хокукый актлар, Җирлек оештыручы булып торган оешмаларның хокукый статусын билгеләүче муниципаль норматив хокукый актлар, шулай ук җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләр рәсми рәвештә игълан ителгәннән соң үз көченә керә.

2. Муниципаль норматив хокукый актның, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүнең рәсми игълан ителүе булып аларның:

1) Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru) тулы текстны рәсми бастырып чыгару; массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык ЭЛ № ФС77-60244 17.12.2013 ел., элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәт (Роскомнадзор) яисә «Туган як» («Таванен») район газетасында (29.05.2020 еелдан Эл № ФС 77- 78420 теркәлүе турында таңыклык;);
2) Чүпрәле муниципаль районы авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштыру (https://drogganoye.tatarstan.ru/);
3) Торак пункт территориясендә урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштыру: Иске Чүпрәле авылы, 2 нче бишьеллык урамы, 5 нче йорт; Иске Чүпрәле авылы, Зеленая урамы, 1Б йорт; Иске Чүпрәле авылы, Газ урамы, 17 нче йорт;

Иске Чүпрәле авылы, Үзәк урам, 14 нче йорт; Яңа Чүпрәле авылы, Яшьлек ур., 17 нче йорт; Иске Әлмәле авылы, Үзәк урамы, 23 нче йорт.

3. Муниципаль норматив хокукый актлар, җирле үзидарә органнары арасында төзелә торган килешүләр, муниципаль хокукый актлардан яки Федераль закон белән чикләнгән мәгълүматлар булган аерым нигезләмәләрдән тыш, имзаланганнан соң 3 көн эчендә игълан ителә.

4. Җирлек советының салымнар һәм җыемнар турындагы норматив хокукый актлары Россия Федерациясе Салым кодексына ярашлы рәвештә үз көченә керә.

5. Әлеге статьяның 1 пунктында күрсәтелмәгән муниципаль хокукый актлар, әгәр акт үзе башканы билгеләмәсә, имзаланган көннән үз көченә керә.

6. Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә тиешле сайтларның доменнарын һәм муниципаль хокукый актларны, шул исәптән җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүләрне, халыкка игълан итү (рәсми бастырып чыгарудан тыш) гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чаралары буларак аларны теркәү турында белешмәләрне күрсәтеп, вакытлы матбугат басмалары, челтәр басмалары исемлеге Җирлек башлыгының хокукый актын бастырып чыгару юлы белән гомуми игътибарга җиткерелә.»

**82 статьяның 1 пунктында 9 һәм 9_1 пунктчаларын** түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законда, «Коррупциягә каршы көрәш турында» 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль законда һәм башка федераль законнарда каралган белешмәләрне тапшырмау яисә муниципаль хезмәткә кергәндә белә торып дөрес булмаган яисә тулы булмаган белешмәләр тапшыру;

9-1) «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законның 15_1 статьясында каралган белешмәләрне тапшырмау.

Татарстан Республикасы
Чүпрәле муниципаль районы
Иске Чүпрәле авыл җирлеге башлыгы: М.Р. Гафаров